**III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**ИЛЛЕ ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Зеленая Роща авылы

20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә
муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар
(иҗтимагый фикер алышулар)
оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»
Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның
14 февралендәге Зеленая Роща авыл җирлеге
Советының XXXXXI сессиясенең
№3 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп

**Зеленая Роща авыл җирлеге Советы**

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Зеленая Роща авыл җирлеге Советының XXXXXI сессиясенең №3 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 4 бүлектә:

*- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:*

«4. Халык алдында тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районының Зеленая Роща авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районының « Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы («Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча үткәрелә.

Зеленая Роща авыл җирлеге советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Зеленая Роща авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге

Башлыгы инициативасы буенча үткәрелүчесе («Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) – «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Зеленая Роща авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Д.М. Хикмәтов**